**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

«26» сентябрь 2022 ел № 406

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Опушка авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Кече Шилнә» авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2022 елның 27 окябренә 19.30 сәгатькә Тукай муниципаль районы Опушка авылында Лесная урамы буенча 1 йорт янында Опушка авылының Лесная ур., Речная ур., буенча үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенын уздыру өчен Опушка авылында яшәүчеләр исемлеген бүлүне территориаль билге буенча башкарырга.

3. Гражданнар җыенына чыгарылган мәсьәләне расларга:

««2023 елда яшәү урыны буенча Кече Шилнә авыл җирлеге Опушка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, I, II төркем инвалидларыннан һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан тыш, 3000 (оч мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

1) балалар-спорт һәм җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү;

2)Опушка авылында юлларны ремонтлау

«ӘЙЕ» «ЮК».

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы А.Г. Даутов